## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

18 нче ноябрь, 2020 № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 17 ноябрендә 14 сәгатьтә, 2020 елның 17 ноябрендә 16 сәгатьтә , 2020 елның 18 ноябрендә 11 сәгатьтә, 2020 елның 18 ноябрендә 18 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

-территориядәге санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләрне чистарту;

-материаллар сатып алып ,чишмә төзекләндерү;

- материаллар сатып алып , күпер ремонтлау;

- материаллар сатып алып , су насосын алыштыру ;

- материаллар сатып алып, янгын гидрантларын урнаштыру;

- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре (участокны межалау һәм җиргә таныклык алу яки Росреестрда теркәү белән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен рәсмиләштерү, скважиналар паспортларын торгызу, гидрогеологик бәяләмә төзү, санитар саклау зоналары проектын төзү, проект нигезендә скважиналар һәм санитар саклау зоналарын төзү, гигиена һәм эпидемиология үзәге федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесендә суны анализлау “Санитар саклау зоналары” һәм “Эчәр су” зоналарында СанПин нормаларына экспертиза үткәрү, санитар-эпидемиология нәтиҗәләре алу);

- материаллар сатып алып ,юлларны норматив хәлгә китерү;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.»

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсҗәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 335 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -179, бу 53,4 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 179 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

-территориядәге санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләрне чистарту;

-материаллар сатып алып ,чишмә төзекләндерү;

- материаллар сатып алып , күпер ремонтлау;

- материаллар сатып алып , су насосын алыштыру ;

- материаллар сатып алып, янгын гидрантларын урнаштыру;

- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре (участокны межалау һәм җиргә таныклык алу яки Росреестрда теркәү белән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен рәсмиләштерү, скважиналар паспортларын торгызу, гидрогеологик бәяләмә төзү, санитар саклау зоналары проектын төзү, проект нигезендә скважиналар һәм санитар саклау зоналарын төзү, гигиена һәм эпидемиология үзәге федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесендә суны анализлау “Санитар саклау зоналары” һәм “Эчәр су” зоналарында СанПин нормаларына экспертиза үткәрү, санитар-эпидемиология нәтиҗәләре алу);

- материаллар сатып алып ,юлларны норматив хәлгә китерү;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.»

3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” гы 2020 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарын гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Зиннәтуллин Р.Р.